**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592)
7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс
(885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__13__» ___03___ 2025 ел.** **№ __74__**

«2024 елгы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында»гы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү хакында

Азнакай муниципаль районында яшәүчеләрнең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын яклау максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уставының 16 статьясы, Азнакай муниципаль районы Советының 2018 елның 22 августындагы 203-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында»гы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы»нда гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, карар бирә:

1. «2024 елгы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында»гы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү инициаторы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге Башлыгы.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2024 елның 11 апрелендә 17.30 сәгатьтә;
- үткәрү урыны-Азнакай шәһәре, Ленин ур., 22 йорт (зур утырышлар залы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган адрес-Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетын үтәү турында»гы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының гамәлдәге законнар, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытта карар проекты буенча гавами тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга.

5. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетының 2024 елгы үтәлеше турында»гы Азнакай муниципаль районы Советы карар проекты буенча гавами

тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркем) составын кушымта нигезендә расларга.

6. 2025 елның 19 мартыннан да соңга калмыйча, 2024 елгы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында»Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар проектын Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы аппараты җитәкчесе А.Х. Хәлиуллинга йөкләргә.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
Башлыгы карарына кушымта
«______» __________ 2025 №_______

**«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетының 2024 елгы үтәлеше турында»гы Азнакай муниципаль районы Советы карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү буенча оештыру комитеты (эшче төркем) составы**

*Оештыру комитеты (эшче төркем) рәисе:*

| | |
|---|---|
| А.Х. Шәмсетдинов | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

*Оештыру комитеты (эшче төркем) секретаре:*

| | |
|---|---|
| Серегина О.Б. | «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнең фаразлау һәм икътисадый анализ бүлеге баш белгече |

*Оештыру комитеты әгъзалары (эшче төркем):*

| | |
|---|---|
| Гурьянова Л.К. | «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» МКУ рәисе |
| Габитова З.С. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| Галиева Ф.Г. | Татарстан Республикасы Азнакай район Советы депутаты, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Башлыгы |
| Рәшитова М.М. | Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |